РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.12.2025

№ 361

Аксубаево

"Татарстан Республикасы Аксубай районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе нигезләмәсен һәм составын раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай районы Башкарма комитетының 23.05.2025 № 136 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Аксубай районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе нигезләмәсен һәм составын раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай районы Башкарма комитетының 23.05.2025 № 136 карарына үзгәрешләр кертелергә, 1 нче кушымтаның 4.10 пункты түбәндәге редакциядә бирелергә:

«4.10. Комиссия утырышында секретарь протокол үткәрә. Протоколда Комиссия исеме, утырыш көне, протокол номеры, утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары саны һәм исемлеге, көн тәртибе чагылыш табарга тиеш.

Протоколга карала торган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге, алар буенча кабул ителгән карар, кирәк булганда, конкрет мәсьәләләр буенча Комиссия әгъзаларының аерым фикере кертелә.

Протокол Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Протокол утырыш яки киңәшмә узган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

Комиссия протоколлары архив эше турындагы законнар нигезендә саклана".

2. Бу карар Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырылсын һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырылсын.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче: С.Ю.Зайцев